КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 47

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын оптимальләштерү һәм аларны гамәлгә ашырганда бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт программаларын оптимальләштерү һәм аларны гамәлгә ашырганда бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын оптимальләштерү һәм аларны гамәлгә ашырганда бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын оптимальләштерү һәм аларны гамәлгә ашырганда бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составын.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 28 гыйнвар, 47 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын оптимальләштерү һәм аларны гамәлгә ашырганда бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы дәүләт программаларын оптимальләштерү һәм аларны гамәлгә ашырганда бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын (алга таба – дәүләт программалары) гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләүне караганда республика башкарма хакимият органнары, бюджет акчасы белән бүтән баш итүчеләр һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте хезмәттәшлеген тәэмин итү максатында төзелгән даими эшләүче координация органы булып тора.

2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Бурычлар һәм функцияләр

3. Комиссиянең төп бурычы – дәүләт программаларын һәм аларның структур элементларын гамәлгә ашыру барышы турында һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында җыелма еллык докладны, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кызыксынучы республика башкарма хакимият органнарының, бюджет акчасы белән бүтән баш итүчеләрнең бирелгән өстәмә материалларын исәпкә алып әзерләнгән, дәүләт программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән тәкъдимнәрне карап тикшерү.

4. Үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен Комиссия түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

4.1. Дәүләт программаларын һәм аларның структур элементларын гамәлгә ашыру барышы турында һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында җыелма еллык докладны карап тикшерә.

Дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы турында һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында җыелма еллык докладны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия тарафыннан түбәндәге тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин:

чираттагы финанс елы башланганга кадәр чираттагы финанс елына һәм план чорына дәүләт программасына һәм (яисә) аның структур элементларына үзгәрешләр кертү турында, шул исәптән дәүләт программасын һәм (яисә) аның структур элементларын гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләменә һәм (яисә) гамәлгә ашыру срокларына үзгәреш кертү турында;

дәүләт программасын һәм (яки) аның структур элементларын гамәлгә ашыруны төгәлләү турында;

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасының бюджеттан тыш фондлары чыгымнарын оптимальләштерү турында;

планлаштырыла торган күрсәткечләргә һәм чараларга (нәтиҗәләргә) ирешмәгән өчен дәүләт программаларын үтәүчеләргә карата законнарда каралган җаваплылык чараларын куллану турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Рәисе адресына җибәрү турында.

Комиссия тәкъдимнәре хисап елыннан соң килә торган елның 15 мартына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына алга таба идарә карарларын кабул итү өчен җибәрелә.

4.2. Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 1014 номерлы указларында, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрнең үтәлеше өчен җаваплы координаторлар һәм республика башкарма хакимият органнары исемлеген раслау турында» 2021 елның 19 мартындагы 116 номерлы боерыгында билгеләнгән социаль-икътисадый үсешнең максатчан күрсәткечләре динамикасына, шулай ук аларны ирешү ысулларына һәм этапларына кагылышлы мәсьәләләрне карый.

4.3. Дәүләт программаларын һәм аларның структур элементларын гамәлгә ашыру рискларын бәяләүгә, шул исәптән күрсәткечләрнең һәм чараларның (нәтиҗәләрнең) максатчан зурлыкларына ирешүгә, дәүләт контрактларын төзүгә һәм үтәүгә, финансларны үзләштерүгә кагылышлы мәсьәләләрне карый. Дәүләт программаларын һәм аларның структур элементларын гамәлгә ашыру рискларына карата эш итү чаралары турында тәкъдимнәр формалаштыра.

4.4. Дәүләт программаларын һәм (яки) аларның структур элементларын оптимальләштерүгә һәм нәтиҗәлелеген арттыруга бәйле башка мәсьәләләрне карап тикшерә.

5. Бурычларны һәм функцияләрне үтәү кысаларында Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

республика башкарма хакимият органнарыннан, бюджет акчасы белән бүтән баш итүчеләрдән һәм башка оешмалардан Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмат, документлар һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

үз утырышларында Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләрен һәм вәкилләрен, бюджет акчасы белән бүтән баш итүчеләрне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм башка оешмалар әгъзаларын тыңларга;

Комиссия эшендә катнашу өчен кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары вәкилләрен, бюджет акчасы белән бүтән баш итүчеләрне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм башка оешмалар әгъзаларын билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

Татарстан Республикасы Рәисе яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары таләп ителә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне билгеләнгән тәртиптә бирү турында тәкъдимнәр ясарга.

## III. Комиссия төзү

6. Комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Комиссия түбәндәге составта төзелә: Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия әгъзалары һәм Комиссия секретаре.

7. Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары арасыннан билгеләнә.

Комиссия секретаре республика башкарма хакимият органнары вәкилләре арасыннан билгеләнә.

8. Комиссия рәисе:

Комиссия эшчәнлеген җитәкли һәм Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җавап бирә;

Комиссия эшен һәм аның утырышлары чакырылышын оештыра;

Комиссия утырышларын үткәрәү датасын һәм вакытын билгели;

Комиссия утырышында рәислек итә;

Комиссия әгъзалары арасында бурычларны бүлә.

Комиссия рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

9. Комиссия секретаре:

Комиссия утырышын үткәрүне әзерләү һәм оештыруны гамәлгә ашыра;

Комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра;

Комиссия утырышларына материаллар җыюны һәм әзерләүне, Комиссия тәкъдимнәре проектларын әзерләүне оештыра;

Комиссия утырышы үткәрелә торган көнгә кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Комиссия әгъзаларына һәм чакырылган затларга Комиссия утырышын үткәрү турында хәбәрнамә һәм Комиссия утырышында каралачак мәсьәләләр буенча материаллар (мәгълүмат) җибәрә;

Комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә.

10. Комиссия әгъзалары:

Комиссия утырышларында катнаша һәм Комиссия утырышының көн тәртибендә күрсәтелгән мәсьәләләрне тикшерә;

Комиссия эше барышында үзләренә мәгълүм булган хезмәт, коммерция яки салым серен тәшкил итә торган белешмәләрне фаш итәргә хокуксыз;

Комиссия утырышларында карала торган мәгълүматны һәм башка материалларны карау хокукына ия.

## IV. Комиссия эшчәнлеген оештыру

11. Комиссия эше очрашу формасында гамәлгә ашырыла.

Комиссия утырышлары кирәк булуга карап, әмма кимендә елга бер тапкыр уздырыла.

Комиссия утырышы, әгәр анда аның составының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия әгъзалары булмаган чорда, аларның вазыйфаларын үтәү аларны алыштыручы (аларның бурычларын үтәүче) затларга йөкләнә.

12. Комиссия әгъзалары Комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

Комиссия тәкъдимнәре утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең яки аның вазыйфаларын башкаручы Комиссия рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч була.

13. Комиссия тәкъдимнәре Комиссия утырышы үткәрелгән көннән алып өч көн эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә, Комиссия рәисе урынбасары белән килештерелә һәм Комиссия рәисе (Комиссия утырышында рәислек итүче) белән раслана.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 28 гыйнвар, 47 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын оптимальләштерү һәм аларны гамәлгә ашырганда бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры, комиссия рәисе урынбасары |
| Корчашкина Гөлнара Сәлахетдин кызы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны координацияләү бүлеге башлыгы |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Кудрявцева Алевтина Николаевна | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Насыртдинов Олег Рәшит улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Сираҗиева Сәрия Салих кызы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары |
| Шишкин Алексей Геннадьевич | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Якунин Леонид Александрович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе (килешү буенча). |